ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 апрель 2021 ел № 2286

Башкарма комитетның «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 сентябрендәге 5515 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 25 сентябрендәге 5515 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2019 елның 1 ноябрендәге 5655 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 6789 номерлы карарлары редакциясендә), кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2021 елның 2 апрелендәге
2286 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының
җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция
эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль
норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Башкарма комитет тарафыннан эшләнә торган һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яки муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртүче муниципаль норматив хокукый актлар проектларының (алга таба – актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга (алга таба – норматив хокукый актлар) экспертиза үткәрү тәртибен билгели.

2. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатында үткәрелә:

1) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык йөкләмәләр, тыюлар һәм чикләүләр кертү яки аларны барлыкка китерүгә булышлык итү;

2) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының, муниципаль берәмлек бюджетының нигезсез чыгымнарын барлыкка китерүгә булышлык итү;

3) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигезсез кыенлык тудыру;

4) конкурентлыкны нигезсез чикләүгә булышлык итү.

3. Җайга салу йогынтысын бәяләү, эшчәнлекләре өлкәсенә эшләнә торган акт проекты кагыла торган Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары (алга таба – профильле бүлекчә) тарафыннан гамәлгә ашырыла. Акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү турындагы бәяләмәне әзерләү Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе (алга таба – вәкаләтле бүлекчә) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү профильле бүлекчә тарафыннан әзерләнә торган акт проектындагы нигезләмәләрнең җайга салу йогынтысының дәрәҗәсен исәпкә алып үткәрелә:

1) җайга салу йогынтысының югары дәрәҗәсе – акт проекты эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затлар өчен элек законнарда каралмаган йөкләмәләр, тыюлар һәм чикләүләрне билгели торган нигезләмәләрне, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затларның элек законнарда каралмаган чыгымнарын барлыкка китерүгә китерә торган нигезләмәләрне үз эченә ала;

2) җайга салу йогынтысының уртача дәрәҗәсе – акт проекты эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затлар өчен элек законнарда каралган йөкләмәләр, тыюлар һәм чикләүләрне үзгәртә яки аларны билгеләүгә булышлык итә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затларның элек законнарда каралган чыгымнарын арттыруга китерә торган нигезләмәләрне үз эченә ала;

3) җайга салу йогынтысының түбән дәрәҗәсе – акт проекты әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында каралган нигезләмәләрне үз эченә алмый, әмма әлеге нигезләмә нигезендә аның җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиеш.

5. Вәкаләтле бүлекчә актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм норматив хокукый актларга экспертиза үткәрүне методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

6. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү түбәндәгеләргә карата үткәрелми:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының җирле салымнар һәм җыемнарны билгели, үзгәртә, туктата, гамәлдән чыгара торган норматив хокукый актлары проектларына;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актлары проектларына;

3) гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектларына.

7. Норматив хокукый актларга экспертиза бәяләмәсен әзерләү, норматив хокукый актларга экспертиза үткәрүнең еллык планы нигезендә вәкаләтле бүлекчә тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Норматив хокукый актларга экспертиза эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигезсез кыенлык тудыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатында үткәрелә.

9. Норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Башкарма комитет Җитәкчесенең йөкләмәсе;

2) эшмәкәрлек, инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге иҗтимагый оешмалардан, кулланучылар берләшмәләреннән, үз-үзен җайга салучы оешмалардан, фәнни-эксперт оешмалардан тәкъдимнәр;

3) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә проблемалар булуны профильле бүлекчә тарафыннан мөстәкыйль рәвештә ачыклау, шул исәптән түбәндәгеләр нәтиҗәсендә:

- норматив хокукый актлар мониторингы;
- муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый хәленә мониторинг;
- гражданнардан һәм оешмалардан эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы актлар проектларында һәм норматив хокукый актларда проблемалар булуны раслаучы мөрәҗәгатьләр керү.

10. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү өчен рәсми сайт булып Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайты www.nabchelny.ru (алга таба – шәһәрнең рәсми сайты) тора.

## 2 бүлек. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү

11. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү түбәндәге этаплардан тора:

1) җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү өчен акт проектын һәм аңа җыелма хисап әзерләү;

2) акт проекты буенча җәмәгать консультацияләре үткәрү;

3) акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмә әзерләү.

12. Җыелма хисап түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

1) актлар проектының җайга салу йогынтысы дәрәҗәсе;

2) хәл итү өчен муниципаль җайга салу юнәлдерелгән проблемага тасвирлама;

3) хәзерге вакытта алар нигезендә муниципаль җайга салу гамәлгә ашырыла торган норматив хокукый актлар яки аларның аерым нигезләмәләре;

4) норматив җайга салуның максатлары;

5) муниципаль җайга салу юнәлдерелгән эшмәкәрлек, инвестиция эшчәнлеге субъектларының төп төркемнәренә характеристика;

6) җирле үзидарә органының яңа функцияләре, вәкаләтләре, бурычлары һәм хокуклары яки аларның үзгәрүе турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тормышка ашыру тәртибе;

7) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар яки чикләүләр яисә гамәлдәге бурычларның һәм чикләүләрнең эчтәлеге үзгәрү, шулай ук аларның үтәлешен оештыру тәртибе;

8) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының, эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының билгеләнгән бурычларны яки чикләүләрне үтәү зарурлыгына яисә әлеге бурычларның яки чикләүләрнең эчтәлеге үзгәрүгә бәйле чыгымнарын (мөмкин булган керемнәрен) бәяләү;

9) муниципаль җайга салу максатларына ирешү мониторингының ачыкланган проблеманы чагылдыручы индикаторлары (күрсәткечләре), җайга салу өлкәсендәге проблеманы анализлау моментына әлеге индикаторларның зурлыгы һәм индикаторларның зурлыгы турында мәгълүматларның чыганаклары;

10) акт проекты үз көченә керүнең күздә тотылган датасы;

11) җайга салуның куелган максатларына ирешү өчен кирәкле оештыру-техник, методологик, мәгълүмати һәм башка чаралар;

12) эшләүче фикере буенча, тәкъдим ителә торган норматив җайга салуның нигезлелеген бәяләргә мөмкинлек бирүче башка мәгълүматлар.

Җыелма хисапны профильле бүлекчә җитәкчесе имзалый.

13. Профильле бүлекчә, җыелма хисап имзаланганнан соң өч эш көне эчендә, шәһәрнең рәсми сайтында «Җайга салу йогынтысын бәяләү» бүлегендә түбәндәге мәгълүматны урнаштыра:

1) җәмәгать консультацияләре үткәрү турында белдерү;

2) акт проекты;

3) җыелма хисап.

14. Җәмәгать консультацияләре үткәрү турындагы белдерү кәгазе профильле бүлекчә җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) норматив хокукый актның исеме һәм үз көченә керүнең планлаштырылган срогы;

2) тәкъдимнәр кабул ителүнең башлану датасы һәм тәмамлану срогы һәм аларны тапшыруның уңайлырак ысулы;

3) җәмәгать консультацияләрендә катнашучылар өчен сораулар исемлеге.

15. Профильле бүлекчә, шәһәр сайтында материаллар урнаштыру белән бер үк вакытта, түбәндәге органнарга җәмәгать консультацияләре башлану турында хәбәр итә:

1) вәкаләтле бүлекчәгә;

2) эшчәнлекләренең максаты булып эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының мәнфәгатьләрен яклау торган оешмаларга;

3) профильле бүлекчә фикере буенча, акт проектының җәмәгать консультацияләренә җәлеп итү максатка ярашлы булган оешмаларга, эшмәкәрлек җәмгыяте вәкилләренә.

16. Профильле бүлекчә тарафыннан җәмәгать консультацияләре үткәрүнең сроклары җайга салу йогынтысы түбән дәрәҗәдәге актлар проектлары буенча 10 календарь көн, җайга салу йогынтысы урта дәрәҗәдәге буенча – 20 календарь көн, җайга салу йогынтысы югары дәрәҗәдәге буенча белдерү кәгазендә күрсәтелгән датадан башлап 20 календарь көннән ким булмаган һәм 30 календарь көннән артмаган срокта.

17. Җәмәгать консультацияләренең нәтиҗәләре белешмә формасында рәсмиләштерелә. Белешмәдә тәкъдимнәрнең авторы, эчтәлеге, аларны исәпкә алу турында мәгълүматлар яки кире кагу сәбәпләре күрсәтелә.

18. Җәмәгать консультацияләрен үткәрү нәтиҗәләре буенча, профильле бүлекчә акт проектын эшләп бетерә һәм җыелма хисапны тулыландыра. Җыелма хисапка өстәмә рәвештә түбәндәгеләр кертелә:

1) җәмәгать консультацияләрен үткәрү, үткәрү сроклары, әлеге Нигезләмәнең 14 пункты нигезендә җәмәгать консультацияләре үткәрү турында хәбәр ителгән оешмалар турында мәгълүматлар;

2) әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында каралган белешмә.

19. Эшләнеп беткән акт проекты һәм тулыландырылган хисап проекты, бәяләмә әзерләү өчен, җәмәгать консультацияләре тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә вәкаләтле бүлекчәгә җибәрелә.

20. Вәкаләтле бүлекчә акт проекты һәм җыелма хисап кергән көннән башлап 10 эш көненнән артмаган срокта бәяләмәне әзерли. Бәяләмә әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә вәкаләтле бүлекчә җитәкчесе тарафыннан имзалана. Бәяләмә имзаланган көннән башлап 3 эш көненнән дә соңга калмый, профильле бүлекчәгә җибәрелә һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.

21. Уңай бәяләмә алган очракта, профильле бүлекчә Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Эш регламенты нигезендә акт проектын килешенү процедурасын үткәрә.

22. Вәкаләтле бүлекчә тарафыннан акт проектында әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләр ачыкланган очракта, профильле бүлекчә бәяләмәне алган көннән башлап 20 эш көне эчендә акт проектын һәм җыелма хисапны эшләп бетерә һәм әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә каралган процедураларны кабат үткәрә.

## 3 бүлек. Норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү

23. Норматив хокукый актка экспертиза үткәрүнең этаплары булып түбәндәгеләр тора:

1) норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү планын (алга таба – план) формалаштыру;

2) норматив хокукый акт буенча җәмәгать консультацияләре үткәрү;

3) норматив хокукый актка экспертиза үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү.

24. Планда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) норматив хокукый актның исеме һәм реквизитлары;

2) норматив хокукый актны эшләүне гамәлгә ашыручы профильле бүлекчәнең исеме;

3) норматив хокукый актка экспертиза үткәрү срогы.

25. Вәкаләтле бүлекчә, агымдагы ел тәмамланганчы дүрт айдан да соңга калмый, рәсми сайтта план формалаштыру максатларында тәкъдимнәр җыю турында белдерү урнаштыра.

26. Тәкъдимнәр җыю срогы 60 календарь көнне тәшкил итә. Башкарма комитет Җитәкчесе тәкъдимнәр җыю тәмамланганнан соң 7 эш көне эчендә алдагы елга планны раслый. План, ул расланган көннән башлап 3 эш көненнән дә соңга калмый, рәсми сайтта урнаштырылырга тиеш.

27. Экспертиза үткәрүнең расланган еллык планы нигезендә, норматив хокукый акт планда билгеләнгән срокларда профильле бүлекчә тарафыннан җәмәгать консультациясенә чыгарыла. Җәмәгать консультацияләре үткәрү өчен, профильле бүлекчә шәһәрнең рәсми сайтында «Җайга салу йогынтысын бәяләү» бүлегендә түбәндәге мәгълүматны урнаштыра:

1) җәмәгать консультацияләре үткәрү турында белдерү;

2) норматив хокукый акт;

3) аңлатма язуы.

28. Белдерү кәгазе җәмәгать консультацияләре үткәрүнең башлану һәм тәмамлану даталарын, җәмәгать консультацияләрендә катнашучыларның үз фикерләрен юллау ысулларын, җәмәгать консультацияләрендә катнашучылар өчен сораулар исемлеген үз эченә алырга тиеш. Өстәмә рәвештә әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында күрсәтелгән органнар һәм оешмаларга хәбәр җибәрелә.

29. Норматив хокукый актка аңлатма язуы түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

1) норматив хокукый актның төп реквизитлары;

2) норматив хокукый актны кабул иткән һәм (яки) компетенцияләренә һәм вәкаләтләренә җәмәгать мөнәсәбәтләренең тикшерелә торган өлкәсе караган органның исеме;

3) акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар (үткәрелгән очракта);

4) норматив хокукый актта билгеләнгән җайга салу белән кызыксынган затлар даирәсе;

5) проблеманы хәл итү һәм җайга салу хисабына аның белән бәйле тискәре нәтиҗәләрне җиңеп чыгу дәрәҗәсен бәяләү;

6) әлеге норматив хокукый актны тормышка ашырудан чыгымнарны һәм керемнәрне бәяләү;

7) җайга салуның фактик уңай һәм тискәре нәтиҗәләрен бәяләү;

8) җайга салуның билгеләнгән максатларына һәм күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәлелеген бәяләү;

9) норматив хокукый актта эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигезсез кыенлык тудыра торган нигезләмәләр булу турында мәгълүматлар;

10) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигезсез кыенлык тудыра торган нигезләмәләрне бетерү һәм гамәлдәге җайга салу нәтиҗәлелеген күтәрү ысуллары турында тәкъдимнәр;

11) җайга салуның фактик йогынтысын бәяләргә мөмкинлек бирүче башка мәгълүматлар.

30. Норматив хокукый акт буенча җәмәгать консультацияләре белдерү кәгазендә күрсәтелгән датадан башлап 20 календарь көннән ким булмаган һәм 30 календарь көннән артмаган срокта үткәрелә.

31. Профильле бүлекчә җәмәгать консультацияләренең нәтиҗәләре буенча кергән барлык тәкъдимнәрне карап тикшерә һәм аларны исәпкә алу кирәклеген күрсәтеп тәкъдимнәр керү яки кире кагу сәбәпләре турында белешмә төзи.

32. Профильле бүлекчә, җәмәгать консультацияләре тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә, бәяләмә әзерләү өчен җәмәгать консультацияләре үткәрү нәтиҗәләре буенча белешмә теркәлгән аңлатма язуын вәкаләтле бүлекчәгә җибәрә.

33. Вәкаләтле бүлекчә, белешмә теркәлгән аңлатма язуы кергән көннән башлап 10 эш көненнән артмаган срокта, норматив хокукый актка экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерли. Бәяләмә әзерләнгәннән соң 3 эш көне эчендә вәкаләтле бүлекчә җитәкчесе тарафыннан имзалана. Бәяләмә имзаланган көннән башлап 3 эш көненнән дә соңга калмый профильле бүлекчәгә җибәрелә һәм рәсми сайтта урнаштырыла.

34. Вәкаләтле бүлекчә тарафыннан норматив хокукый актта әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләр ачыкланган очракта, экспертиза нәтиҗәләре турындагы бәяләмә норматив хокукый актка үзгәрешләр кертү яки аны гамәлдән чыгару өчен нигез булып тора.

35. Профильле бүлекчә бәяләмәне алган көннән башлап 20 эш көне эчендә, Шәһәр Советының 2017 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган

Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәгә туры китереп, норматив хокукый актка үзгәрешләр кертү яки аны гамәлдән чыгару процедурасын үткәрә.

36. Үзгәрешләр кертелгәннән соң, профильле бүлекчә акт проекты буенча әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә каралган процедураларны үткәрә.

## 4 бүлек. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм норматив хокукый актларга экспертиза үткәргәндә фикер каршылыкларын хәл итү

37. Тискәре бәяләмә нәтиҗәсендә акт проекты яки норматив хокукый акт проекты буенча фикер каршылыклары булган очракта, профильле бүлекчә тискәре бәяләмә алган көннән башлап 15 эш көненнән дә соңга калмый киңәшмә оештыра.

38. Фикер каршылыкларын хәл итү Башкарма комитет Җитәкчесе кызыксынган затлар катнашында үткәргән киңәшмәдә башкарыла, анда ахыргы карар кабул ителә.

39. Киңәшмәдә кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә, киңәшмә үткәрү датасыннан башлап 3 эш көненнән дә соңга калмый, профильле бүлекчә тарафыннан төзелә. Беркетмә киңәшмәдә рәислек итүче зат тарафыннан имзалана.

40. Фикер каршылыкларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар профиль һәм вәкаләтле бүлекчәләр өчен мәҗбүри булып тора һәм беркетмәдә күрсәтелгән срокта үтәлергә тиеш.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева